| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 8 ноябре № 13

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге бюджеты проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 15 августындагы 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, иҗтимагый берләшмәләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджеты проекты (алга таба – җирлек бюджеты проекты) буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты.

3. Билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты-2024 елның 10 декабре 14.00 сәгатьтә;

3.2. гавами тыңлаулар урыны – Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 1б йорт, КФҮ;

3.3. җирлек бюджеты проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы күрсәтелгән адрес – Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 1б йорт, эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр тәкъдим итəлергә мөмкин;

3.4. җирлек бюджеты проекты буенча гаризалар кабул итү сроклары - 2024 елның 7 декабренә кадәр;

3.5. җирлек бюджеты проектын халыкны таныштыру өчен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный поселогы,Гагарин ур., 5нче йорт; Иске Писмән ав., Үзәк ур., 50нче йорт-Иске Писмән мәдәният йорты адресы буенча урнаштырырга.

4. Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына:

4.1. билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар оештырырга һәм уздырырга;

4.2. гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) җирлек бюджеты проектын тапшырырга;

4.3. 2024 елның 13 декабренә кадәр җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтына (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5. Җирлек бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәрне Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный поселогы,Гагарин ур., 5нче йорт; Иске Писмән ав., Үзәк ур., 50нче йорт-Иске Писмән мәдәният йорты адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына 2024 елның 29 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный поселогы,Гагарин ур., 5нче йорт; Иске Писмән ав., Үзәк ур., 50нче йорт-Иске Писмән мәдәният йорты, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) игълан итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге» башлыгы Н.В.Дементьев